| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**28.10.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 21** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче һәм өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү нормалары турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 9 июлендәге 847/0 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче һәм өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирүнең кушымтада бирелгән нормаларын расларга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бирү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре исемлегенә кертелгән барлыкка килгән җир кишәрлекләренә карата кулланылмый дип билгеләргә.

3. Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар төшенчәсе Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацындагы мәгънәсендә кулланыла дип билгеләргә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалтуын таныргa:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә унсигез яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк баласы булган, шул исәптән үги балалары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән йә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында индивидуаль торак төзелешен, дача хуҗалыгын алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хосусый милеккә ия булган җирләрдән милек буларак бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге 125 номерлы,
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек аларга карата вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга

муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән, шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 30 декабрендәге 473 номерлы,

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган (опека һәм попечительлек аларга карата вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) гражданнарга муниципаль милектәге җирләрдән милеккә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән, шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен раслау турында» 2011 елның 30 декабрендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге 473 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) » 2023 елның 30 маендагы 280 номерлы.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru/) сайтында игълан итәргә (бастырырга).

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы ,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск Советының
2025 елның 28 октябрендәге
21 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәүче һәм өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү нормалары:

(кв.м)

| | Зелено-дольск шәһәре | Васильево штп | Түбән Карамалы штп | Авыл җирлекләре, Осиново авылыннан тыш | Осиново авылы |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Индивидуаль торак төзелеше | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 |
| Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару | - | - | - | 1000 | 1000 |
| Бакчачылык | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 |
| Яшелчәчелек | 600 | 600 | 1000 | 1000 | 600 |